СОВЕТ
СИЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д. 1, с.Смак-Корса,
Арский муниципальный район, 422025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕЖЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Мәктәп урамы, 1 йорт, Курса Почмак авылы,
Арча муниципаль районы, 422025

Тел. (84366)93-1-24, факс (84366)93-1-24. E-mail: Smk.Ars@tatar.ru

**Сеже авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**№ 99** **“21” август 2019 ел**

**Сеже авыл җирлеге Советының 2017 елның 27 октябрендәге 48 номерлы «Җир салымы турында " карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 31 бүлек, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеже авыл җирлеге Уставы нигезендә Сеже авыл җирлеге Советы КАРАР бирде:

1. Сеже авыл җирлеге Советының 2017 елның 27 октябрендәге 48 номерлы «Җир салымы турында» карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

-2 нче пунктның 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару өчен алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә, шулай ук 2017 елның 29 июлендәге «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләренә карата 0,1процент.”

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында рәсми басылып чыккан көннән соң бер айдан гына үз көченә керә.

Сеже авыл җирлеге башлыгы Г.М.Гыйбадуллина